**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Сосновый Бор поселогында (иске өлеш) гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

24 ноябрь, 2022ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда яшәү урыны буенча Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы (иске өлеш ) территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:
- Сосновый Бор т. п. яктырткычлар сатып алу, монтажлау һәм урам утларын урнаштыру (Иске өлеш);
- Сосновый Бор т. п. СИП - кабель сузу ( Иске өлеш);
- Сосновый Бор т. п. (Иске өлеш) юлларны ремонтлау.
- Сосновый Бор т. п. (Иске өлеш) суүткәргечне ремонтлау

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **714** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **411** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **404** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **7** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы (иске өлеш) гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2023 елда яшәү урыны буенча Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы (иске өлеш) территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз

илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Сосновый Бор т. п. яктырткычлар сатып алу, монтажлау һәм урам утларын урнаштыру (Иске өлеш);
- Сосновый Бор т. п. СИП - кабель сузу ( Иске өлеш);
- Сосновый Бор т. п. (Иске өлеш) юлларны ремонтлау.
- Сосновый Бор т. п. (Иске өлеш) суүткәргечне ремонтлау

3. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын Князево авыл җирлеге территориясендә теркәлгән взнослардан азат итәргә.

4. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы (иске өлеш) гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

5. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Сосновый Бор поселогы (иске өлеш) гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кнәз авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Камалов